**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 7 август № 574

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 ноябрь, 917 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 ноябрь, 917 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 июнь, 494 нче, 2012 ел, 30 июль, 646 нчы, 2014 ел, 8 октябрь, 733 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «конкурс яки аукцион нәтиҗәләре буенча» сүзләрен «җир асты байлыклары турында законнарда билгеләнгән тәртиптә» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре гомум таралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомум таралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яки тәңгәлләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын табу өчен яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү һәм аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгару белән бәйле булмаган

максатларда, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә файдалануга биреләләр.»;

6 пунктта «Рәсмиләштерү» сүзләреннән соң «, яңадан рәсмиләштерү» сүзләрен өстәргә;

7 пунктта:

текстка түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«җир асты суларын чыгару – 25 елга кадәр;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Файдалы казылмалар чыгару белән бәйле булмаган, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен файдаланыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре чикләнмәгән вакытка бирелергә мөмкин.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Җир асты байлыкларыннан бу файдаланучы тарафыннан лицензия шартларын бозу булмаган шартларда, гомум таралган файдалы казылмалар чыганагын эзләүне һәм бәяләүне яки эшкәртүне тәмамлау яисә бетерү чараларын һәм җирләрне яңадан эшкәртүне башкару кирәк булган очракта җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану вакыты җир асты байлыкларыннан файдаланучы башлангычы белән озайтыла.»;

10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бетерү яки консервацияләү процессы тәмамланганчы җир асты байлыкларыннан файдаланучы үзенә «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә йөкләнгән җаваплылык тота.»;

11 һәм 12 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Үзләренә «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә бирелгән кысаларда бүлеп бирелгән таулы урыннарда һәм (яки) геологик бүлеп бирелгән урыннарда файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгаруны яки тәңгәлләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар расланган техник проект нигезендә түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үзенең җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен гомум таралган файдалы казылмалар чыгаруны гамәлгә ашырырга;

үзенең җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен җир асты байлыклары дәүләт фонды белән идарә итүче федераль орган билгеләгән тәртиптә җир асты суларын чыгаруны гамәлгә ашырырга.

12. Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр, җир кишәрлекләрен арендалаучылар әлеге җир кишәрлекләре чикләрендә шартлату эшләрен кулланмыйча үз ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре чикләрендә булган һәм дәүләт балансында исәпләнмәгән гомум таралган файдалы казылмалардан, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү чыганаклары булмаган һәм үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү чыганагы булган су бирү горизонтлары

өстендә урнашкан су горизонтларыннан чыгару күләме тәүлегенә 100 куб.метрдан артмаска тиеш җир асты суларыннан файдаланырга, шулай ук законнарда һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә биш метрга кадәр тирәнлектә җир асты корылмаларын төзергә хокуклы.

Әлеге статья максатларында үз ихтыяҗлары өчен гомум таралган файдалы казылмалардан һәм җир асты суларыннан файдалану дигәндә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр, җир кишәрлекләрен арендалаучылар тарафыннан шәхси, көнкүреш һәм бүтән эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган ихтыяҗларда файдалану күздә тотыла.

Җир кишәрлекләре чикләрендә булган һәм җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр, җир кишәрлекләрен арендалаучылар тарафыннан шәхси, көнкүреш һәм бүтән эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган ихтыяҗларда файдаланылган гомум таралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары тартып алына һәм бер заттан икенчесенә күчә алмый.»;

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

«Моннан тыш, җир асты байлыкларыннан файдаланучылар салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән башка салымнар һәм җыемнар түлиләр.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Файдалы казылмалар чыганакларын эшкәртү (эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яки сәнәгать объектларын яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм чыгару күләмнәре тәүлегенә 100 куб.метр тәшкил иткән җир асты суларын чыгарудан гайре) һәм файдалы казылмалар чыгару белән бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану расланган техник проектлар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

17 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Файдалы казылмалар чыгару һәм эшкәртү, файдалы казылмалар чыгару белән бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану буенча проектларны төзү һәм тормышка ашыру җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләр шартлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Файдалы казылмаларны еллык чыгару дәрәҗәсе җир асты байлыклары турында Россия Федерациясе законнары нигезендә чыганакны эшкәртүгә проект документы белән билгеләнә.

Җир асты байлыкларыннан файдалануның расланган техник проектына һәм шартларына үзгәрешләр кертмичә генә гомум таралган файдалы казылмаларны гамәлдәге еллык чыгаруның проекттагы чыгарудан тайпылышы әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада китерелгән күләмнәрдә рөхсәт ителә. Әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада китерелгән тайпылышлардан тайпылу бары тик җир асты байлыкларыннан файдалануның расланган техник проектына һәм шартларына үзгәрешләр кертү белән генә рөхсәт ителә.»;

23 пунктның 3 пунктчасында «кушымта нигезендә» сүзләрен «1 нче кушымта нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

24 пунктта:

2 пунктчада «казылма табуның таулы урыннары» сүзләреннән соң «, скважиналар» сүзләрен өстәргә;

3 пунктчада «билгеләнгән тәртиптә» сүзләреннән соң «(гомум таралган файдалы казылмалар өчен)» сүзләрен өстәргә;

6 пунктчада «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «(гомум таралган файдалы казылмалар өчен)» сүзләрен өстәргә;

7 пунктчада «Россия Федерациясе» сүзләреннән соң «(гомум таралган файдалы казылмалар өчен)» сүзләрен өстәргә;

күрсәтелгән Тәртипкә кушымтада:

санлы исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
территориясендә җирле
әһәмияттәге җир асты байлыклары
кишәрлекләреннән файдалану
тәртибенә 1 нче кушымта»;

күрсәтелгән Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле 2 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы
территориясендә җирле
әһәмияттәге җир асты байлыклары
кишәрлекләреннән файдалану
тәртибенә 2 нче кушымта

Җир асты байлыкларыннан файдалануның расланган техник проектына һәм шартларына үзгәрешләр кертмичә генә гомум таралган файдалы казылмаларны гамәлдәге еллык чыгаруның проекттагы чыгарудан тайпылышлары

| Гомум таралган файдалы казылмаларны проекттагы еллык чыгару (мең куб.метр, мең тонна) | Гамәлдәге еллык чыгаруның проекттагы чыгарудан тайпылышы зурлыгы (процент) |
|---|---|
| 50 гә кадәр | 30 |
| 50 дән 200 гә кадәр | 25 |
| 200 дән артык | 20». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\574.docx